ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дмитрова, д.2,
с.Ютаза, 423962

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Дмитров урамы, 2 йорт,
Ютазы авылы, 423962

Тел.:(85593) 4-00-91, факс:4-00-93, e-mail: Utaz.Utz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**№22А** **«04» август 2015 ел**

Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге
Башкарма комитетының 2015 елның 27 февралендәге
5 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2014 елның 22 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы 431-ФЗ санлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 23 мартындагы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында»гы ПУ-308 санлы Указы нигезендә һәм коррупциягә каршы тору буенча эшчәнлекне камилләштерү максатларында, Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты карар итә:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 27 февралендәге «Гражданнарны билгеләгәндә һәм аларны алмаштырганда муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук хатынының (тормыш иптәшенең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлеген раслау турында»гы 5 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) преамбуланың атамасында 1 пунктында, «гражданнар билгеләгәндә һәм” сүзләрен алып ташларга;

б) муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегендә гражданнарны билгеләгәндә һәм аларны алмаштырганда муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Ютазы авыл җирлеге башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы:
Г.Г.Сәфиуллина